ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 26 гыйнварында
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Конституциясенә (2002 елның 19 апрелендәге 1380 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 9 – 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 3 – 4; 2003, № 9 (I өлеш); 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2010, № 3, № 11; 2012, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Татарстан Республикасы – Россия Федерациясе составындагы демократик хокукый дәүләт. Татарстан Республикасы дәүләтчелеге, Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләрдән һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе вәкаләтләреннән тыш, дәүләт хакимиятенең бөтен тулылыгына Татарстан Республикасының ия булуында, аның үз территориясе, халкы, дәүләт хакимияте органнары системасы, үз Конституциясе һәм законнары, дәүләт телләре һәм дәүләт символлары булуында чагыла.»;

2) 3 статьяда:
а) беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Татарстан Республикасында хакимият аның күпмилләтле халкы тарафыннан турыдан-туры, шулай ук дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары аша гамәлгә ашырыла.»;
б) икенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«6 статья**

Татарстан Республикасы Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә биргән вәкаләтләр чикләрендә халыкара һәм тышкы икътисадый бәйләнешларны гамәлгә ашыра, тиешле килешүләр төзи, вәкиллекләр алмаша, халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнаша.»;

4) 9 статьяда:

а) икенче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә, «Татарстан Республикасы судлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче өлештә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләренә алмаштырырга;

5) 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«12 статья**

Татарстан Республикасында идеологик күптөрлелек танылa. Бернинди идеология дә дәүләтнеке яисә мәҗбүри буларак билгеләнә алмый.»;

6) 15 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 21 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

8) 24 статьяда:

а) беренче өлештә «хокукый системасында» сүзләрен «хокукый актлары системасында» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче өлештә «Басылып чыкмаган законнар» сүзләрен «Басылып чыкмаган Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга, «норматив хокукый акт» сүзләрен «Татарстан Республикасы норматив хокукый акты» сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасында халыкара хокукның Россия Федерациясе хокукый системасының состав өлеше булган гомумтанылган принциплары һәм нормалары кулланыла.»;

9) 25 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«25 статья**

Федераль законнарда каралган очракларда һәм тәртиптә Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә төзелергә мөмкин.»;

10) 29 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Социаль, расачыл, милли билгеләр, тел яисә дин билгеләре буенча гражданнарның хокукларын чикләүнең теләсә кайсы рәвеше тыела.»;

11) 33 статьяның икенче өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

12) 50 статьяның өченче өлешендә «законда» сүзен «федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

13) 51 статьяда икенче җөмләне төшереп калдырырга;

14) 52 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«52 статья**

1. Татарстан Республикасында һәркем, медицина ярдәмен дә кертеп, сәламәтлеген саклауга хокуклы. Медицина ярдәме дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау учреждениеләрендә гражданнарга тиешле бюджет акчалары, иминият кертемнәре, башка акчалар исәбеннән түләүсез күрсәтелә.

2. Татарстан Республикасы һәркем өчен мөмкин булган һәм сыйфатлы медицина ярдәме күрсәтүне, җәмәгать сәламәтлеген саклауны һәм ныгытуны, сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен шартлар тудыруны, гражданнарның үз сәламәтлегенә җаваплы каравы культурасын булдыруны тәэмин итә.»;

15) 56 статьяның икенче өлешендә «мәктәпкәчә,» сүзеннән соң «башлангыч гомуми,» сүзләрен өстәргә, «башлангыч» сүзен «урта гомуми белем» сүзләренә алмаштырырга;

16) 67 статьяда «иң югары вәкиллекле, закон чыгару органы» сүзләрен «вәкиллекле һәм бердәнбер закон чыгару органы» сүзләренә алмаштырырга;

17) 69 статьяда:

а) икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Россия Федерациясендә даими яшәүче, чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булмаган, закон нигезендә пассив сайлау хокукына ия булган һәм 21 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты булып сайланырга мөмкин.»;

б) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү тәртибе федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җайга салына.»;

в) түбәндәге эчтәлекле дүртенче өлеш өстәргә:

«4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм федераль закон нигезендә актив сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан сайлана.»;

18) 70 статьяда:

а) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә тиеш.»;

б) дүртенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) алтынчы өлешнең икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

19) 71 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«71 статья**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы һәм аның эшчәнлеге гарантияләре федераль закон һәм Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

20) 72 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«72 статья**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә, Татарстан Республикасы Премьер-министрына, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләренә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан төзелә яисә сайлана торган башка органнарның вазыйфаи затларына (Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларыннан тыш), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына таләп белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Үзенә таләп җибәрелгән орган яисә вазыйфаи зат законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда телдән яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты таләбе буенча язмача җавап бирергә тиеш.»;

21) 73 статьяда:

а) беренче өлештә «сайланганнан соң» сүзләрен «сайланган көннән алып» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле өченче өлеш өстәргә:

«3. Яңа чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшли башлаган көннән алып элеккеге чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре туктатыла.»;

22) 75 статьяда:

а) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 5 пунктта «, Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты проектын карау» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) озак сроклы чорга Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеше стратегиясен һәм Татарстан Республикасында стратегик планлаштыруны гамәлгә ашыру тәртибен раслау;»;

г) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) Татарстан Республикасының бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларын һәм Татарстан Республикасының бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары үтәлеше турындагы хисапларны раслау;»;

д) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм федераль законнарда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарын оештыру тәртибен һәм аларның эшчәнлек тәртибен билгеләү;»;

е) 13 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

ж) 16 пунктта «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

з) 17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17) федераль закон һәм әлеге Конституция нигезендә Татарстан Республикасы Рәисенә ышанычсызлык белдерү турында карар кабул итү;»;

и) 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18) Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Премьер-министрын һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларын билгеләп кую турындагы тәкъдимнәрен килештерү;»;

к) 21 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

л) $22^1$ пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

м) 23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23) федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне билгеләп кую;»;

н) түбәндәге эчтәлекле $23^1$ пункт өстәргә:

«$23^1$) федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне билгеләп кую;»;

о) түбәндәге эчтәлекле $24^1$ пункт өстәргә:

«$24^1$) Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисен, Рәис урынбасарын һәм аудиторларын билгеләп кую;»;

п) 25 пунктта «сайлау округларын төзү» сүзләрен «сайлау округлары» сүзләренә алмаштырырга;

р) 28 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

с) 30 пунктта «, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәрен билгеләү» сүзләрен төшереп калдырырга;

т) 31 пунктта «эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу» сүзләрен «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы

дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү» сүзләренә алмаштырырга;

23) 76 статьяда:

а) беренче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе,» сүзләрен «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе һәм» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Салымнар (җыемнар) билгеләү, аларны гамәлгә кертү яисә гамәлдә булуларын туктату, салым ставкаларын (җыемнар ставкаларын), салымнар (җыемнар) түләү тәртибен һәм срогын үзгәртү, салым ташламаларын (җыемнар буенча ташламаларны) билгеләү (юкка чыгару) һәм (яисә) аларны куллану нигезләрен һәм тәртибен билгеләү турындагы Татарстан Республикасы законнары проектлары, финанс белән тәэмин ителеше Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган чыгымнарны күздә тотучы башка Татарстан Республикасы законнары проектлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдиме буенча йә аның бәяләмәсе булганда карала. Әлеге бәяләмә закон проектын алган көннән алып 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшырыла.»;

24) 77 статьяда:

а) икенче өлештә «Татарстан Республикасы законнары» сүзләреннән соң «һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары» сүзләрен өстәргә, «әлеге Конституциядә» сүзләрен «законнарда» сүзенә алмаштырырга;

б) өченче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

25) 79 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«79 статья**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кабул иткән Татарстан Республикасы законы 14 календарь көн эчендә Татарстан Республикасы Рәисенә җибәрелә.

2. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы законы кергән вакыттан алып 14 календарь көн эчендә аңа имза сала һәм аны халыкка җиткерә йә аны кире кага. Күрсәтелгән срок, әгәр Россия Федерациясе Президенты тарафыннан Россия Федерациясе Конституция Судына кабул ителгән Татарстан Республикасы законының конституциячеллеген тикшерү турында таләп җибәрелгән булса, туктатылып тора.

3. Татарстан Республикасы законын кире каккан очракта, Татарстан Республикасы Рәисе аны, ризасызлыклары белән бергә, кабат карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кире кайтара. Татарстан Республикасы законы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кире кагылган очракта, күрсәтелгән

закон элек кабул ителгән редакциясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесенең күпчелек тавышы белән хупланырга мөмкин.

4. Элек кабул ителгән редакциясендә хупланган Татарстан Республикасы законы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кабат кире кагыла алмый, җиде календарь көн эчендә аңа имза салынырга һәм ул халыкка җиткерелергә тиеш.»;

26) 81 статьяда «Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасының бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары үтәлешен,» сүзләрен өстәргә;

27) 84 статьяда:

а) 4 пунктта «Татарстан Республикасы» сүзләре алдыннан «закон нигезендә» сүзләрен өстәргә;

б) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Татарстан Республикасы Конституциясендә, Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында каралган очракларда башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

в) 6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

28) 87 статьяда «дәүләт контролен» сүзләрен «тышкы дәүләт финанс контролен» сүзләренә алмаштырырга;

29) 88 статьяда:

а) беренче өлештә:

беренче абзацта «туктатылырга мөмкин» сүзләрен «туктатыла» сүзенә алмаштырырга;

1 пунктта «үз-үзен таркату» сүзләрен «үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт Советын закон нигезендә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Дәүләт Советын федераль закон һәм әлеге Конституция нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә «үз-үзен таркату» сүзләрен «үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» сүзләренә алмаштырырга;

в) өченче өлештә «Үз-үзен таркату турында карар кабул иткәндә» сүзләрен «Әлеге статьяның беренче өлешендәге 1 пункты нигезендә үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул иткәндә,» сүзләренә, «үз-үзен таркату турындагы» сүзләрен «үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату хакындагы» сүзләренә алмаштырырга;

г) дүртенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

д) бишенче өлештә «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганда, Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтләре әлеге статьяның беренче

өлешендәге 2 пункты нигезендә вакытыннан алда туктатылганда, Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

30) 2 бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 БҮЛЕК. **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ**»;

31) 89 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«89 статья**

1. Татарстан Республикасы Рәисе дәүләт башлыгы, Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты була.

2. Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасының исеме – Татарстан Республикасы Рәисе.»;

32) 90 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«90 статья**

Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауның, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә, Татарстан Республикасы шартнамәләре һәм килешүләре үтәлешенең гаранты булып тора.»;

33) 91 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«91 статья**

1. Россия Федерациясендә даими яшәүче, чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булмаган, закон нигезендә пассив сайлау хокукына ия булган һәм 30 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданы Татарстан Республикасы Рәисе булып сайланырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм федераль закон нигезендә актив сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан гомуми тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш биреп сайлана.

3. Татарстан Республикасы Рәисе биш елга сайлана.

4. Татарстан Республикасы Рәисен сайлауларны әзерләү һәм үткәрү тәртибе федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җайга салына.»;

34) 92 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«92 статья**

1. Татарстан Республикасы Рәисе федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә тиеш.

2. Татарстан Республикасы Рәисе, үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, Татарстан Республикасы дәүләт телләрен куллана.»;

35) 93 статьяда:

а) беренче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

в) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Рәисе, үз вазыйфасына керешкәндә, Татарстан Республикасы халкына һәм Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә тугрылыклы булырга түбәндәге рәвештә ант итә: «Татарстан Республикасының күпмилләтле халкына тугрылыклы хезмәт итәргә, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итәргә, Россия Федерациясе Конституциясен һәм Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәргә, Татарстан Республикасы Рәисенең миңа йөкләнгән югары вазыйфаларын намус белән үтәргә тантаналы төстә ант итәм».»;

г) дүртенче өлештә «, Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) бишенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Рәисе Штандарты (флагы) була.»;

36) 94 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«94 статья**

1. Татарстан Республикасы Рәисе:

1) Татарстан Республикасында гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, Татарстан Республикасы дәүләтчелеген яклауны, билгеләнгән чикләрдә аның территориясен саклауны, Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать иминлеген, законлылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итә;

2) Татарстан Республикасында башкарма хакимияткә җитәкчелек итә һәм аның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән хезмәттәшлеген тәэмин итә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгели;

3) Татарстан Республикасының эчке сәясәтен һәм тышкы эшчәнлек юнәлешләрен билгели;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына карау һәм раслау өчен ел саен Татарстан Республикасы бюджеты турындагы һәм аның үтәлеше хакындагы законнарның проектларын тәкъдим итә;

5) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына озак сроклы чорга Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеше стратегиясен тәкъдим итә;

6) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына республиканың эчке һәм тышкы хәле турындагы еллык юллама белән мөрәҗәгать итә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына республика тормышының мөһим мәсьәләләре хакында мәгълүмат бирә;

7) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эшчәнлек нәтиҗәләре турында еллык хисапларны, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы куйган мәсьәләләр буенча, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү хакында җыелма еллык докладны тәкъдим итә;

8) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын төзи, аның эшчәнлегенә җитәкчелек итә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының отставкасы турында карар кабул итә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән килештереп, Татарстан Республикасы Премьер-министрын, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларын билгеләп куя, Татарстан Республикасы министрларын, Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары рәисләрен, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары җитәкчеләрен билгеләп куя. Татарстан Республикасы Премьер-министрын, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларын, Татарстан Республикасы министрларын, Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары рәисләрен, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары җитәкчеләрен вазыйфаларыннан азат итә;

9) Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасын һәм структурасын билгели;

10) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе вазыйфасына кандидатураны тәкъдим итә;

11) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатураны тәкъдим итә;

12) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатураны тәкъдим итә;

13) федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне вазыйфасына билгеләп куя;

14) Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларының яртысын билгеләп куя;

15) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе Дәүләт Советы, башка органнар, оешмалар һәм вазыйфаи затлар белән мөнәсәбәтләрдә һәм Татарстан Республикасы компетенциясе чикләрендә халыкара, тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы исеменнән эш йөртә; Татарстан Республикасы исеменнән шартнамәләргә һәм килешүләргә имза сала; Россия Федерациясендә, аның субъектларында, чит дәүләтләр субъектларында һәм административ-территориаль берәмлекләрендә, шулай ук чит дәүләтләрдә һәм халыкара оешмаларда Татарстан Республикасы вәкилләрен билгеләп куя һәм чакыртып ала;

16) Татарстан Республикасы законнарына имза сала һәм аларны халыкка җиткерә йә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кабул иткән законнарны кире кага;

17) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасы Рәисе указларына каршы килгән очракта, аларны юкка чыгара;

18) Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкли;

19) Татарстан Республикасы премияләрен гамәлгә куя һәм аларны тапшыра;

20) Татарстан Республикасында ярлыкау мәсьәләләрен карау комиссиясен төзи һәм ярлыкау акты кулланунының максатка ярашлылыгы турында Россия Федерациясе Президентына тәкъдим кертә;

21) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттан тыш утырышын чакыруны таләп итәргә, шулай ук яңа сайланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советын беренче утырышка шуның өчен билгеләнгән срок эчендә чакырырга хокуклы;

22) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы эшендә киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашырга хокуклы;

23) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары белән эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, Россия Федерациясендә гавами хакимиятнең бердәм системасына керә торган башка органнар белән хезмәттәшлеген оештыра;

24) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, Россия Федерациясе карамагындагы эшләр һәм Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы эшләр буенча кабул ителгән федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килүче Татарстан Республикасы Конституциясе һәм (яисә) Татарстан Республикасы законы, башка норматив хокукый акт кабул ителгән очракта, әгәр, мондый каршылыклар тиешле суд тарафыннан билгеләнгән булып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы суд карары үз көченә кергән көннән алып алты ай эчендә аларны бетермәгән булса, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул итә;

25) федераль законнар һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен алар тарафыннан гамәлгә ашыруны тәэмин итү бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен муниципаль берәмлек башлыгына, җирле администрация башлыгына кисәтү ясарга, шелтә белдерергә хокуклы;

26) муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы әлеге статьяның беренче өлешендәге 25 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе

муниципаль берәмлек башлыгына, җирле администрация башлыгына кисәтү ясаган, шелтә белдергән көннән алып бер ай эчендә үз вәкаләтләре чикләрендә аңа кисәтү ясау, шелтә белдерү өчен нигез булган сәбәпләрне бетерү чараларын күрмәсә, муниципаль берәмлек башлыгын, җирле администрация башлыгын вазыйфасыннан читләштерергә хокуклы;

27) федераль законда билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына муниципаль берәмлек башлыгын отставкага җибәрү инициативасы белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы, шул исәптән җирле үзидарә органнарының эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренә даими рәвештә ирешмәгән очракта да;

28) Татарстан Республикасы Рәисе Штандарты (флагы) турындагы нигезләмәне раслый;

29) Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы шартнамәләре һәм килешүләре нигезендә бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Татарстан Республикасы Рәисе үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен үз Администрациясен төзи, аның Җитәкчесен билгеләп куя.»;

37) 95 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә, «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсе» сүзләрен «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә, федераль конституциячел законнар» сүзләренә алмаштырырга;

38) 96 статьяда «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

39) 97 статьяда:

а) беренче өлештә:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы» сүзләре алдыннан «Россия Федерациясе Президентының ышанычын югалтуга яисә» сүзләрен өстәргә;

б) икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләре Россия Федерациясе Президентының карары яисә Россия Федерациясе Президенты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»;

в) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Рәисенә түбәндәге очракта ышанычсызлык белдерергә хокуклы:

ул Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына каршы килүче актлар чыгарганда, әгәр, мондый каршылыклар тиешле суд тарафыннан билгеләнгән булып, Татарстан Республикасы Рәисе суд карары үз көченә кергән көннән алып бер ай эчендә әлеге каршылыкларны бетермәсә;

Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль конституциячел законнарны, федераль законнарны, Россия Федерациясе Президенты указларын, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын, Татарстан Республикасы законнарын башкача тупас бозу тиешле суд тарафыннан билгеләнгәндә, әгәр бу гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен массакүләм рәвештә бозуларга китерсә;

Татарстан Республикасы Рәисе үз вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгәндә.»;

г) дүртенче өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

д) бишенче өлештә «Президентка» сүзен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

е) алтынчы өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

40) 98 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«98 статья**

1. Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яисә аны вакытлыча вазыйфасыннан читләштергән очракларда Россия Федерациясе Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы Рәисе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы турында указ чыкканчы, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе үз вәкаләтләрен сәламәтлеге хәленә яисә үз вәкаләтләрен башкаруга вакытлыча комачаулаган башка хәлләргә бәйле рәвештә башкара алмаган очракта, Татарстан Республикасы Рәисе вазыйфаларын вакытлыча Татарстан Республикасы Премьер-министры башкара.

2. Федераль законда билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасы Рәисе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләп куела.

3. Әлеге статьяның беренче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Татарстан Республикасы Дәүләт Советын таркатырга, Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында тәкъдимнәр кертергә, шулай ук үз инициативасы белән Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларын һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләрен вазыйфаларыннан азат итәргә хокуксыз.»;

41) 99 статьяда:

а) беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте – иң югары даими эшләүче Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы.»;

б) икенче өлештә «Татарстан Республикасы законы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга;

42) 100 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«100 статья**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан төзелә, һәм аны Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары, Татарстан Республикасы министрлары, Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары рәисләре тәшкил итә. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары җитәкчеләрен кертә ала.

2. Татарстан Республикасы Премьер-министры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәисе була һәм аның эшен оештыра.

3. Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән килештереп, Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләп куела.»;

43) 101 статьяда:

а) беренче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче өлештә «Премьер-министр урынбасарларына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларына» сүзләренә алмаштырырга, икенче җөмләне төшереп калдырырга;

44) 102 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«102 статья**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) финанс, фән, мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт, социаль тәэминат, юл хәрәкәте иминлеге һәм экология өлкәләрендә бердәм дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша;

2) кешенең һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру, тәэмин итү һәм яклау, милекне һәм җәмәгать тәртибен саклау, терроризмчылыкка һәм экстремистлыкка каршы тору, җинаятьчелеккә каршы көрәш чараларын күрә;

3) Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүгә юнәлдерелгән чараларны эшләүне һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

4) Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының этномәдәни күптөрлелеген, телләрен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү, милли азчылыкларның хокукларын яклау, мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләү, милләтара (этникара) низагларны профилактикалау һәм милләтара, конфессияара татулыкны тәэмин итү чараларын күрә;

5) сәламәтлек саклау мәсьәләләрен координацияләү, шул исәптән һәркем өчен мөмкин булган һәм сыйфатлы медицина ярдәме күрсәтү, җәмәгать сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен шартлар тудыру, гражданнарның үз сәламәтлегенә җаваплы каравы культурасын булдыру, чараларын күрә;

6) халыкны социаль яклауның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү чараларын, социаль тәэминатны да кертеп, гражданнарга адреслы социаль ярдәм чараларын күрә;

7) гаиләне, ана булуны, ата булуны һәм балачакны яклауны, ир-атның һәм хатын-кызның берлеге буларак никах институтын яклауны тәэмин итү, балаларны гаиләдә лаеклы итеп тәрбияләү, шулай ук балигъ булган балаларның үз ата-аналарын кайгырту бурычын башкару өчен шартлар тудыру чараларын күрә;

8) Татарстан Республикасы бюджеты проектын әзерли;

9) Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тәэмин итә һәм аның үтәлеше турында хисапны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эшчәнлек нәтиҗәләре хакында еллык хисапны, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында җыелма еллык докладны аларны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итү өчен әзерли;

10) Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы милкенә идарә итә һәм аның белән эш итә, шулай ук федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы идарәсенә тапшырылган федераль милеккә идарә итә;

11) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карамагындагы стратегик планлаштыру документларын әзерләү һәм төзәтү тәртибен билгели һәм мондый документларны раслый (хуплый);

12) җирле үзидарә органы, җирле үзидарәнең вазыйфаи заты тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына һәм бүтән норматив хокукый актларына каршы килә торган хокукый актлар чыгарылган очракта, җирле үзидарә органына, җирле үзидарәнең вазыйфаи затына аларны законнарга туры китерүне тәкъдим итә, шулай ук судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы;

13) Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары турында нигезләмәләр раслый;

14) Татарстан Республикасы Конституциясендә, федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, федераль башкарма хакимият органнары белән килешүләрдә, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимияте

органнарына федераль башкарма хакимият органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тапшыруны күздә тотучы Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

45) 103 статьяда «Татарстан Республикасы Конституциясенең,» сүзләреннән соң «федераль конституциячел законнарның,» сүзләрен өстәргә;

46) 105 статьяның икенче өлешендә «һәм дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

47) 4 бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 БҮЛЕК. **СУД ХАКИМИЯТЕ. ПРОКУРАТУРА. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СОВЕТЫ**»;

48) 107 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«107 статья**

Татарстан Республикасында суд хакимияте федераль судлар һәм Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

49) 108 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

50) 109 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

51) 110 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

52) 112 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

53) 114 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«114 статья**

Прокуратура органнары вәкаләтләре, аларны оештыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибе федераль закон белән билгеләнә.»;

54) түбәндәге эчтәлекле $114^1$ статья өстәргә:

**«$114^1$ статья**

Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкны ныгыту максатларында Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция советы төзелергә мөмкин.»;

55) 115 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«115 статья**

Гражданнарның һәм оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында, шул исәптән хөкем итүне гамәлгә ашырганда, аларга юридик ярдәм адвокатлар һәм башка затлар тарафыннан закон нигезендә күрсәтелә.»;

56) 116 статьяда:

а) беренче өлештә «, закон нигезендә һәм үзенә җаваплылык алып,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) икенче өлештә «, җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре үз рәсми символларын билгеләргә хокуклы.»;

57) 117 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«117 статья**

1. Җирле үзидарә муниципаль берәмлекләрдә гамәлгә ашырыла, аларның төрләре федераль закон белән билгеләнә. Муниципаль берәмлекләр территорияләре тарихи һәм башка җирле традицияләрне исәпкә алып билгеләнә.

2. Җирле үзидарә органнары структурасы федераль законда билгеләнгән Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары нигезендә халык тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

3. Җирле үзидарә гамәлгә ашырыла торган территорияләрнең чикләрен үзгәртү тиешле территорияләр халкының фикерен исәпкә алып рөхсәт ителә һәм Татарстан Республикасы законы белән гамәлгә ашырыла.

4. Дәүләт хакимияте органнары федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм очракларда җирле үзидарә органнарын төзүдә, җирле үзидарәнең вазыйфаи затларын вазыйфаларына билгеләп куюда һәм вазыйфаларыннан азат итүдә катнашырга мөмкин.»;

58) 118 статьяда:

а) беренче өлештә «билгелиләр» сүзен «кертәләр» сүзенә алмаштырырга, «җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыралар, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга, «, шулай ук федераль закон нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә медицина ярдәменнән файдалана алуны тәэмин итәләр» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле өченче өлеш өстәргә:

«3. Җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясендә гавами хакимиятнең бердәм системасына керәләр һәм тиешле территориядә яшәүче халыкның мәнфәгатьләрендә мәсьәләләрне аеруча нәтиҗәле хәл итү өчен хезмәттәшлекне гамәлгә ашыралар.»;

59) 119 статьяда «дәүләт хакимияте органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү хокукы,» сүзләрен «җирле үзидарә органнары дәүләт хакимияте органнары белән

хезмәттәшлектә гавами функцияләрне башкару нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү хокукы, шулай ук» сүзләренә алмаштырырга;

60) 120 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«120 статья**

Муниципаль хокукый актлар Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, шулай ук Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларына каршы килмәскә тиеш.»;

61) 121 статьяның беренче өлешендә «суверенитетын» сүзен «дәүләтчелеген» сүзенә алмаштырырга, «Татарстан халкының» сүзләрен «Татарстанның күпмилләтле халкы» сүзләренә алмаштырырга;

62) VII кисәккә түбәндәге эчтәлекле $122^1$ статья өстәргә:

**«$122^1$ статья**

Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү, Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы мәсьәлә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән бере булган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары төркеме, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан кертелергә мөмкин.»;

63) 125 статьяда:

а) беренче өлештә «ундүрт календарь көн эчендә Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «14 календарь көн эчендә Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә, «ундүрт календарь көн эчендә» сүзләрен «14 календарь көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

в) өченче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

64) 126 статьяда:

а) беренче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесенең күпчелек тавышы белән элек кабул ителгән редакциядә хупланган Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм

өстәмәләр кертү турындагы закон Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кабат кире кагыла алмый, җиде календарь көн эчендә аңа имза салынырга һәм ул халыкка җиткерелергә тиеш.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешен (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 3 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.
2. Әлеге Закон үз көченә кергәнче кабул ителгән Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка хокукый актларында, аларга тиешле үзгәрешләр кертелгәнче, Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасының «Татарстан Республикасы Президенты» исеме һәм «Татарстан Республикасы Рәисе» исеме бер үк мәгънәгә ия була.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2023 ел, 26 гыйнвар
№ 1-ТРЗ